ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Җир кодексының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 2 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 10 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексының 9 статьясына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр составы Россия Федерациясе Җир кодексы нигезендә билгеләнә.»;

2) түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:
«4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территорияләрендә урнашкан, крестьян (фермер) хуҗалыклары үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалана торган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр составындагы җир кишәрлекләрендә торак йортлар төзү, реконструкцияләү һәм куллану рөхсәт ителми.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2021, № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 1 пунктын юкка чыгарырга;

2) 2 статьяның 3 өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

**3 статья**

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясы 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 25 февраль
№ 6-ТРЗ